ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮГАРЫ ОСЛАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
"ИННОПОЛИС" ШӘҺӘРЕ МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
ГРАЖДАННАРНЫҢ УТЫЗ СИГЕЗЕНЧЕ ҖЫЕНЫ

КАРАР № 1

«21» май 2019 ел Иннополис шәһәре

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы бюджетыннан алына торган башка бюджетара трансфертлар хисабына тормышка ашырыла торган чыгымнар юнәлешен раслау турында

Профессиональ табыш өчен салым буенча салым потенциалы үсешен стимуллаштыру максатларында һәм «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131 номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 28 мартындагы 233 номерлы «Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре бюджетларына башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибен раслау турында» карары нигезендә һәм Югары Ослан муниципаль районы Советының 2010 елның 24 апрелендә кабул ителгән 45-499 номерлы «Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы бюджетыннан Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы җирлекләре бюджетларына җирлекләрнең чыгым йөкләмәләрен үтәүне финанс ягыннан тәэмин итүгә башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибен раслау турында» карары нигезендә

«Иннополис шәһәре» муниципаль берәмлеге халык җыены
карар кылды:

1. «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясындагы 3 пункты нигезендә һәм «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 15 статьясындагы 3 пункты нигезендә авыл җирлегенең җирле әһәмияттәге мәсьәләләрен хәл итүгә Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы бюджетыннан алына торган башка бюджетара трансфертлар чыгымнар юнәлешен расларга.

2.Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru), Югары Ослан муниципаль районының мәгълүмат сайтында, Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында Интернет челтәрендә (http://verhniy-uslon.tatarstan.ru/), шулай ук Иннополис шәһәре мэриясе бинасында урнашкан махсус мәгълүмат стендында урнаштырырга.

3.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземә калдырам.

Рәислек итүче,
Иннополис шәһәре мэры Р.Р.Шагалеев